

Регионнардагы житәкчеләр һәм актив белән очрашуга Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Ботендонья татар конгрессынын Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев, Ботендонья татар конгрессы Башкарма комитеты житәкчесенен беренче урынбасары Марс Тукаев килгән иделәр.
2018 елдан башлап Ботендонья татар конгрессы Россиянен Федераль округларында татарлар белән очрашулар оештыра башлады. Быел әлеге жыеннарнын алтынчысы узды.

Удмуртия Республикасы Тобәк татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Рәмзия Габбасова әлеге очрашунын быелгысы Удмуртия Республикасы башкаласы Ижау шәһәрендә vтvенә шат булуын белдерде. “Бvгенге кондә Удмуртия Республикасында 100 менгә якын татар яши. Алар башка милләтләр белән кулга-кул тотынышып, ярдәмләшеп, аралашып яши һәм берvк вакытта vз телен, динен, мәдәниятен сакларга һәм vстерергә тырыша”, - дип сойләде оешма житәкчесе.
Милли Шура рәисе Васил Шәйх-разыев vзенен чыгышы вакытында оешма житәкчелерәнен бер-берсе белән аралашып, тәжрибә уртаклашуы – әлеге очрашунын топ максаты икәнен ассызыклады.
- Россия тобәкләре буенча сәфәрләребез дәвамлы булсын иде. Үз жирлекләрегездә биредә алган тәжрибәләрегезне дорес кулланырсыз диеп ометләнәбез. Без-беребезгә ярдәм итеп, булган мәгълvматлар белән уртаклашыйк, - диде ул.
Васил Шәйхразыев халык санын алу нәтижәләрендә милләтен кvрсәтмәvчеләр саны 16 миллионнан арткан булуы турында да сойләде:
- Ничек кенә булса да, татарлар Россиядә 5,5 миллионнан ким тvгел дип әйтәбез. Әлбәттә, ковид халык санын алуда безгә зур дошман булды. Әлеге чир кvп кенә олы яшьтәге милләттәшләребез очен кыенлыклар тудырды,-диеп белдерде Милли Шура рәисе.
Чарада Удмуртия Республикасы Милли сәясәт министры Эдуард Петров, Удмуртия Республикасы мофтие, Удмуртия Республикасы Диния нәзарәте рәисе Фәиз хәзрәт Мохәммәтшин, Удмуртия Республикасы Татар ижтимагый оешмасы рәисе Илсур Миннемуллин, “Туган жир” журналы баш мохаррире, Ботендонья татар конгрессынын Милли Шура әгъзасы Дамир Исхаков, фольклорчы, галим Фәнзилә Жәvһәрова, Ульян олкәсе Тобәк татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Рәмис Сафин, Ботендонья татар конгрессы Башкарма комитетынын Башкортстан Республикасындагы вәкиле Альфред Дәvләтшин, Оренбург олкәсе татар милли-мәдәни мохтарияте житәкчесе Илдус Дәvләтов, Ботендонья татар конгрессынын Пермь краендагы вәкиле Сәлим Назин, Киров олкәсе Тобәк татар мәдәни-агарту ижтимагый оешмасы рәисе Рәvф Фәсхетдинов һ.б. чыгыш ясады.
Ульян олкәсе Тобәк татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Рәмис Сафин тобәкләрдәге татар язучыларынын әсәрләрен туплап жыентык итеп бастыру эшен кабат торгызып жибәрvне, шулай ук Россия регионнарындагы татар жырчыларынын чыгышларын Татарстан Яна гасыр телеканалында кvрсәтелә торган концертлар да урын алсын иде

дигән теләкләрен житкерде.
Ботендонья татар конгрессынын Пермь краендагы вәкиле Сәлим Назин халык санын алу нәтижәләре буенча Пермь краенын Барда районында татарлар саны ике тапкыр артуы турында әйтеп узды. Шулай ук ул фольклорчы-галим, шагыйрь Рәшит Ягъфәровнын әсәрләрен китап итеп Татарстанда бастыру очен ярдәм сорап Милли Шура рәисенә морәжәгать итте.
Очрашу ахырында милләтебез алдындагы олы хезмәтләрен искә алып, татар халкынын телен, мәдәниятен vстерvгә, гореф-гадәтләрен саклап калуга коч куйган шәхесләргә Васил Шәйхразыев Ботендонья татар конгрессынын истәлекле бvләкләрен һәм “Энже” балалар бакчасына ноутбук тапшырды.

*Бөтендөнья татар конгрессы матбугат vзэге*